**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 май № 353

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче; 2013 ел, 24 май, 348 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2014 ел, 11 август, 583 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарына беркетелә торган җирле бюджетлар керемнәре чыганаклары исемлеге» кушымтасында:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 8 нче пункт өстәргә:

«8. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына беркетелә торган керемнәр чыганаклары:

1) шәһәр округлары чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә керә торган керемнәр, шулай ук әлеге җир кишәрлекләренең аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акча;

2) авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә керә торган керемнәр, шулай ук әлеге җир кишәрлекләренең аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акча;

3) шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә керә торган керемнәр, шулай ук әлеге җир кишәрлекләренең аренда шартнамәләрен төзү хокукын сатудан акча;

4) шәһәр округлары чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр;

5) авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр;

6) шәһәр җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр;

7) әлеге күчемсез мөлкәт объектлары биләгән шәһәр округлары чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләре белән бергәттән күчемсез мөлкәтне сатудан керемнәр;

8) әлеге күчемсез мөлкәт объектлары биләгән авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләре белән бергәттән күчемсез мөлкәтне сатудан керемнәр;

9) әлеге күчемсез мөлкәт объектлары биләгән шәһәр округлары чикләрендә урнашкан, федераль милектә булган һәм алар белән идарә итү һәм эш итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына бирелгән җир кишәрлекләре белән бергәттән күчемсез мөлкәтне сатудан керемнәр.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2015 елның 21 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков